СОВЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 2а, д.Нижние Аты,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 2а йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

Тел. (84366)50-7-35, факс (84366)50-7-35. E-mail: Sat.Ars@tatar.ru

**Урта Аты авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**30.09.2016** **№ 23**

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2017 елда Урта Аты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә (түләү күләме 150 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, , 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлек территориясен төзеклендерүне оештыру(урам яктырту) | Җирлек территориясен төзеклендерүне оештыру (урам яктырту) - урам утларын алыштыру һәм урнаштыру<br>Түбән Аты авылы<br>Урта Сәрдә авылы<br><br>- каты көнкүреш калдыкларын вакытлыча җыючы урыннарны карап тоту, чүп-чарны трактор белән тыгызлау; торак пунктларда<br>Түбән Аты авылы<br>Урта Сәрдә авылы | <br><br><br>5000<br><br>5000<br><br><br><br><br><br><br>5000<br>5000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларында арата юл эшчәнлеге | - Урта Аты авыл җирлеге составына керә торган юлларга вак таш салу;<br><br>ТУбән Аты Аты авылы, Кече ур., (1-31 йортлар һәм Югары урам 1-5 йорт,һәм 20-24 йортлар)<br>Урта Сәрдә авылы, Югары урам 1-20 йорт<br><br>Кылычы авылы Яшеллек урамы 1-14 йортлар | <br><br><br>112500<br><br><br><br>48900<br><br>18300 |
| 3 | Җирлек чикләрендә су белән тәэмин итүне оештыру | Урта авылда су челтәрләрен ремонтлау Аты күпер ур. | 10000 |
| 4 | Зиратларны карау | Урта Аты авылында зират коймасы тоту | 10000 |
| | Барлыгы | | 224700 |

Экономияләнгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе юк

3. 2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http:pravo.tatarstan.r) гражданнар күплэп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында. : ТР, Арча районы , Түбән Аты авылы , Үзәк урамы, 37 йорт; ТР, Арча районы, Урта Сәрдә авылы, Үзәк урамы, 70 йорт; ТР, Арча районы, Кылачы авылы, Аяк киеме урамы, 16

Урта Аты авыл
җирлеге башлыгы — Мухамадиев Я.З

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «СРЕДНЕАТЫНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СОВЕТ СРЕДНЕАТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609002912